**СОВЕТ СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 8(84378)4-12-91
e-mail:stolb.la@tatar.ru

**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СТОЛБИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нчы йорт,
тел: 8(84378)4-12-91
e-mail:stolb.la@tatar.ru

**2024 елның 29 мае** **61 номер**

# КАРАР

## «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының 2014елның 7 ноябрендәге 25/9 номерлы Столбище авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 7 ноябрендәге 25/9 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге советы карарына (15.05.2015 N 11/2, 15.10.2015 N 3/1, 17.10.2018 N 21/2, 30.10.2018 N 23/3, 08.10.2020 N 3/1номер үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацны:

"Салым ташламасына хокуклы затлар салым органына ташламалар бирү турында гариза, шулай ук салым ташламасына хокукны раслый торган документлар тапшыра."

яңа редакциядә бәян итәргә:

"Салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз сайлавы буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документлар тапшырырга хокуклы."

1.2. 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле 3.4 пунктча өстәргә:

«3.4. Салым ташламасына хокуклы салым түләүчеләр категорияләре Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясында билгеләнгән.»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Столбище**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.Ю. Романова**